ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 март 2019 ел № 1625

Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе 1 бүлегенең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41, 53, 55 маддәләре, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 29 мартындагы
1625 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 1 | Корпоратив кичә оештыру | кеше/2 сәгать | 600,00 |
| 2 | Бәйрәм программасы оештыру | кеше/2 сәгать | 500,00 |
| 3 | Балалар уен программасы, дискотека үткәрү | кеше/сәгать | 200,00 |
| 4 | Балалар тематик программасы үткәрү | кеше/сәгать | 250,00 |
| 5 | Тематик программа үткәрү | 1 чара | 2000,00 |
| 6 | Күңел ачу программасы үткәрү | кеше/сәгать | 100,00 |
| 7 | Кызыксыну буенча клуб оештыру | кеше/2 сәгать | 100,00 |
| 8 | Киноклуб оештыру | кеше/сәгать | 70,00 |
| 9 | Чараны музыка белән алып баруны оештыру | 1 чара | 3000,00 |
| 10 | Чараны видеога төшерүне оештыру | 1 чара | 2000,00 |
| 11 | Семинар үткәрү | 1 семинар | 3000,00 |
| 12 | Мастер-класс үткәрү | 1 мастер-класс | 3000,00 |
| 13 | Күргәзмәләр оештыру | 1 хезмәт | 3000,00 |
| 14 | Костюмлы персонаж хезмәте | 1,5 сәгать | 1500,00 |
| 15 | Гардероб хезмәте күрсәтү | 1 чара | 250,00 |
| 16 | Чара администраторы хезмәте | 1 хезмәт | 500,00 |
| 17 | Хореография концерт номеры | 1 номер | 1200,00 |
| 18 | Вокал концерт номеры | 1 номер | 500,00 |
| 19 | Чараны алып баручы хезмәте | 1 сәгать | 1000,00 |
| 20 | Чара үткәрү өчен режиссерлык-сәхнәгә кую эше | 1,5 сәгать | 2000,00 |
| 21 | Сценарий язу | 1 сенарий | 2000,00 |
| 22 | + форматында фонограмма яздыру | 1 хезмәт | 2000,00 |
| 23 | + форматында фонограмма яздыру (ансамбль) | 1 хезмәт | 3000,00 |
| 24 | Аппаратураны арендага бирү | 1 сәгать | 2250,00 |
| 25 | Микрофонны арендага бирү | 1 сәгать | 500,00 |
| 26 | Экранны арендага бирү | 1 сәгать | 500,00 |
| 27 | Костюмны прокатка бирү | 1 тәүлек | 600,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова